

Чарада район мәдәният vзәгенен ижат коллективлары һәм хезмәткәрләре катнашты.
Бәйрәмнен топ идеясе район һәм республика территориясендә яшәvче халыкларнын мәдәни традицияләрен саклап калу һәм киләчәк буынга тапшыру зарурлыгы булды.
Оч мәйданчыкта торле активлык иде: фойеда Татар-Пешлә модель китапханәсеннән, Мордва-Пешлә клубыннан һәм Мордовиянен комеш волонтерларыннан мастер-класслар, кvргәзмә-сатулар һәм хәтта тобәк җәмәгать сәламәтлеге Үзәге белгечләре тарафыннан халыкка медицина тикшерvе vткәрелде.

Шулай ук “Авылда оныкларга яхшы” фотоконкурсына йомгак ясалды һәм Рузаевкадан “Эра” суши партнеры призлар тапшырды.
“Мәдәниятләр һәм буыннар диалогы” исемле тvгәрәк остәл коллектив житәкчеләрен, мәдәният волонтерлары һәм халык традицияләрен vстерv олкәсендә экспертлар Альфия Максимова, Екатерина Модина, Галина Михотина жыйды. Тvгәрәк остәл артында алар культураны vстерv техникасы һәм ысуллары турында фикер алыштылар.
Аннары Рузаевка районы авыл жирлекләре вәкилләре чыгыш ясады: Гурина Кадрия Габделхак кызы (Татар Пешләсе авылы), Качкалова Людмила Павловна (Перхляй авылы), Глазкова Людмила Алексеевна (Шишкеево авылы). Алар район авылларындагы гореф-гадәтләр турында сойләделәр.
Кадрия Габделхак кызы татар халкынын, Татар Пешлә авылынын мирасы турында жентекләп сойләде.
Бәйрәм зур, якты һәм колоритлы концерт белән тәмамланды: ул оч блоктан торды, аларнын һәркайсы рус, мордва һәм татар халыкларынын милли фольклор номерлары белән тәкъдим ителде.
Бер елдан тагы очрашып, оч мәдәниятнен “Буыннан-буынга” бәйрәмен зур колач белән уздырырга ометләнә оештыручылар.

**Наилә НАСЫРОВА**